РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**КАРАР**
**РЕШЕНИЕ**

26 октябрь 2016ел № 4-11

**«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарында конкурс нигезендә алмаштыручы муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында»**

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары структураларында булган үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Буа муниципаль районы Советының 2015 елның 13 февралендәге 6-45 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарында конкурс нигезендә алмаштыручы муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә» түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 нче пунктның 2 нче бүлегендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы вазыйфасын чыгарырга;

2) 3 пунктның 2 бүлегендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге начальнигы урынбасары вазыйфасыннан чыгарырга;

3) 7 нче бүлектә 1 нче пунктта «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфасын «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфасына үзгәртергә;

4) «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарында конкурс нигезендә алмаштыручы муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә» 9 нчы бүлекне кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 9 бүлек. "Буа муниципаль районы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм идарәсе" муниципаль казна учреждениесендә муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең төп вазифалары:

- «Буа муниципаль районының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы.

2. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазифалары:

- «Буа муниципаль районы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы Рәисе А.К. Айзетуллов